# КАРАР

**27 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча 2020 елның 27 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының нәтиҗәсе буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, балачактан инвалид балалар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Урта Комар авылының Май, Үзәк һәм Яр буе урамнарында янгынга каршы гидрантлар урнаштыру;
- янгын колонкалары һәм рукавлар сатып алу;
- Урта Комар авылында юл полотносын торгызу;
- Урта Комар авылына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Урта Комар авылы урам юл челтәрен карап тоту (кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 183 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 128 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 128 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, балачактан инвалид балалар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм

студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Урта Комар авылының Май, Үзәк һәм Яр буе урамнарында янгынга каршы гидрантлар урнаштыру;
- янгын колонкалары һәм рукавлар сатып алу;
- Урта Комар авылында юл полотносын торгызу;
- Урта Комар авылына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Урта Комар авылы урам юл челтәрен карап тоту (кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Комар
авыл җирлеге башлыгы Ю.И.Исынбаев